| ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БОЛГАР ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ | БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН |
|---|---|

КАРАР ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 11 «29» гыйнвар 2021 ел

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 7 октябрендәге 36 номерлы карары белән расланган (2020 елның 25 маендагы 33 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 125 номерлы үзгәрешләр белән) агач һәм куак кисүгә, кронлауга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» гы Болгар шәһәр Башкарма комитеты 29.01.2021 № 7 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте Идарәсенең уртак коллегиясе беркетмәсен үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының "Болгар шәһәре" муниципаль берәмлеге территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләренә кермәгән, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең 2020 елга Татарстан Республикасы берләштерелгән бюджетын көтелә торган үтәү йомгаклары һәм 2021 елга республика финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга билгеләнгән бурычлары буенча Болгар шәһәр Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитетының «Спас муниципаль районы Болгар шәһәр Башкарма комитеты тарафыннан күрсәтелә торган муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 7 октябрендәге 36 номерлы карары белән расланган (2020 елның 25 маендагы 33 номерлы, 2020 елның 11 декабрендәге 125 номерлы үзгәрешләр белән) агач һәм куак кисүгә, кронлаштыруга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү:

1.1. Регламентның 2.6 пунктын түбәндәге эчтәлекле 2 пунктча белән тулыландырырга:

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә, авария хәлләренә бәйле очраклардан тыш.».

1.2. Регламентның 2.9 пунктын түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча белән тулыландырырга:

4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу».

2. Әлеге карарны закон белән билгеләнгән вакытта Спас _ муниципаль районының рәсми сайтында (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

ТР Спас муниципаль районының
Болгар шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе А.В.Костина

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «ГОРОД БОЛГАР» СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
БОЛГАРСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1637005440